ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.05.2026 Олы Кайбыч ав. № 256

Яшь гаиләләргә торак сатып алуга (төзүгә) бирелә торган социаль түләүләр күләмен исәпләү өчен 2026 елның II кварталына Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы буенча торак гомуми мәйданының бер квадрат метры бәясе нормативын билгеләү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 03 октябрендәге 888 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү» дәүләт программасының «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасын гамәлгә ашыру максатында, ТР Бәяләүчеләр союзының эксперт-консультация советы тарафыннан үткәрелгән ТР Кайбыч муниципаль районында һәм Олы Кайбыч авылында торак биналарның бер квадрат метр бәясенең уртача күрсәткечен билгеләү буенча тикшеренү нәтиҗәләрен (Коммерциясез партнерлыкның «Торак базары турында» 2026 елның 12 февралендәге 43 номерлы хаты) исәпкә алып, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы буенча торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип танылган яшь гаиләләргә 2026 елның II кварталына торак сатып алу яки шәхси торак йорт төзү өчен социаль түләүләр күләмен исәпләү өчен бәя нормативын гомуми торак мәйданының бер квадрат метрына 38168 сум күләмендә билгеләргә.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://kaybici.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең төзелеш һәм ТКХ буенча урынбасары Е.Г. Давыдовага йөкләргә.

Җитәкче А.Н. Макаров